**Каралган**
Педагогик киңәшмә карары №1
29 август 2025 ел

**Раслыйм**
Кошман “Тиенкәй”
балалар бакчасы мөдире
________А.С.Кадырова
Приказ №14   1 сентябрь 2025ел

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 31E0900072B23FB443AE22C94E1DA09A
Владелец: Кадырова Айгуль Салимулловна
Действителен с 27.01.2025 до 27.04.2026

# *Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы “Тиенкәй” балалар бакчасының 2025 – 2026 уку елына укыту-тәрбия планы*

## Кошман“Тиенкәй” балалар бакчасының
## 2024-2025 нче уку елындагы эшчәнлегенә кыскача анализ

2024 -2025 нче уку елында 2 төркемдә барлыгы 40 бала тәрбияләнде һәм белем алды. Ел дәвамында махсус урта белемле 1, югары белемле2 педагог хезмәт куйды.

Балалар бакчасы ел буе балаларга эзлекле белем бирү, физик яктан чыныккан,сәламәт, табигатьне саклый белүне балалар тәрбияләү бурычлары өстендә эшләде.Белем һәм тәрбия бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия бирү учреждениеләренең эшен нәтиҗәле итү өчен яңа идеяләр,белем-тәрбия бирүдә инновацион технологияләр куллану кирәклеген белеп,балаларга тәрбия-белем бирү эшен үз югарылыгында оештырдылар.

Бакчада балаларның физик,интеллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү,иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә игүтибар ителде. Балаларга белем-тәрбия бирүдә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман «Тиенкәй» балалар бакчасы мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесының мәктәпкәчә белем бирү программасы (мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартына яраклаштырылып эшләнгән һәм мәктәпкәчә белем бирүнең федераль белем бирү программасы нигезендә төзелгән (Россия Мәгариф министрлыгының 2022 елның 25 ноябрендәге 1028 номерлы боерыгы белән расланган) комплекслы программа нигезендә алып барылды. Балалар бакчасының балаларга тәрбия-белем бирү планнары, бердәм аралашу эшчәнлеге челтәре һәм календарь планнары СанПиН нормаларына, балаларның сәләтләренә туры китереп төзелде, бакча мөдире тарафыннан расланды һәм гамәлгә кертелде. Тәрбиячеләр, балаларның яшь үзенчәлекләренә туры китереп еллык тематик планнарын төзеп, план буенча эшләрен оештырып, үз теләкләренә ирештеләр.

Балаларның физик, әхлакый, интеллектуаль һәм эстетик үсешләрен үстереп, тулы үсешле шәхес тәрбияләү өчен шартлар тудырып һәм ата-аналар белән тыгыз элемтә булдырдык.

Куелган максаттан чыгып, алдагы уку елында түбәндәге бурычларны куеп эшләдек.

Алынган беренче бурыч буенча ел дәвамында тәрбиячеләр даими рәвештә режим моментларын үтәп, яңа алымнар кулланып эшләделәр.Мәктәпкәчә яшьтәге баланың тулы кыйммәтле яшәеше өчен уңай шартлар тудырылды. Бакчада балаларның физик, интелллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә нык игътибар ителде.

Бакчада балаларны сәламәтләндерү, чыныктыру эшләре быелгы уку елында төрле юнәлештә алып барылды. Иң беренче тәрбияче көндәлек режимны төгәл үтәп, тәрбия - белем бирү эшен дөрес оештырды. Иртәнге гимнастика, физкультура шөгылъләрен тәрбияче ел буена программага нигезләнеп, тиешле дәрәҗәдә алып барды. Физкультура, иртәнге гимнастикаларда гадәти булмаган эш алымнары кулланып эшләүләре, балаларны чыныктыру, сәламәтләндерү эшен яхшыртырга, яхшы нәтиҗәләргә ирешергә зур ярдәм итте.

Бакчада физкультура шөгыле кечкенәләр төркемнәрендә атнага ике, зурлар төркемнәренә өч тапкыр уздырылды, берсе ачык һавада узды.

Физкультура бердәм аралашу эшчәнлегендә тәрбияче иң беренче балаларның активлыгына игътибар итте. Бердәм аралашу эшчәнлекләре уздыру төрләрен үзгәртеп торды, яңалыклар кулланды. Һәр төркемдә бердәм аралашу эшчәнлекләре, буш вакытларда даими рәвештә күз гимнастикасы, аваз әйтү гимнастикалары кертелде.

Ата - аналар белән балаларның сәламәтлеген ныгыту буенча системалы эш оештырылды: чыгышлар ясалды, китап—ширма, папка передвижка тутырылды, китап—эстафеталар ясалды. “Әти, әни, мин — сәламәт гаилә”, ”Сәламәт булыйк”, зурлар төркеме ата-аналары белән юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү буенча күңел ачулар, акцияләр үткәрелде.

Чыныктыру, сәламәтләндерү процедураларын башкарганда тәрбияче түбәндәге рациональ гигиена шартларын һәм таләпләрен төгәл үтәде:

- Һаваның саф булуы;
- бинадагы һава температурасының тиешле дәрәҗәдә булуы;
- киемнәрнең температурага карап дөрес сайлануы;
- хәрәкәт режимының активлыгы.

Менюда ризыклар төрләндерелде, балалар аксымга бай продукцияләр, яшелчә, җиләк-җимешләр белән тукландырылды.

Дөрес туклану, көндәлек режимны, сәламәтлек программасын төгәл үтәү, физкультура, спорт белән даими шөгыльләнү, организмны чыныктыру балаларыбыз сәламәтлегенә уңай тәэсир итте.

Традицион физкультура бердәм аралашу эшчәнлекләре, иртәнге гимнастика, физкультура досуглары,бәйрәмнәре

музыка астында үтә. Бакчабызның икенче бурычы: Балаларны кече яшьтән милли рухта тәрбияләү.Без балаларны мәктәпкә әзерләү белән генә чикләнмичә, һәр яктан шәхес тәрбияләүнең бер юнәлеше булган милли культура формалаштырып, балаларны милли-мәдәни рухыта тәрбияләү буенча узган уку елында төрле юнәлештә эш алып бардык.

Балаларны милли-мәдәни рухта тәрбияләү буенча бакчада "Сөмбелә", "Әнием - минем кадерлем", "Дәү әнием-икенче әнием", "Әтием -горурлыгым", "Нәүрүз", Г.Тукай көненә "Туган телдә сөйләшәбез"дигән темаларга бәйрәм иртәләре, күңел ачу кичәләре уздырылды. Һәр бәйрәмгә әти-әниләр, әбиләр чакырылды. Шулай ук беренче сыйныф укучылары белән дә тыгыз элемтәдә торабыз.

Экология проблемасы үзенең актуальлелеге, үткенлеге белән бүген бөтен кешелек алдына килеп басты. Чөнки киләчәк буыннар язмышын фән-техника казанышлары түгел, ә җир-суларның экологик торышы хәл итәчәк. Экология проблемасының глобаль проблема булып, аның үзебез яши торган урында да чагылуы без –тәрбиячеләрдә борчылу тудыра. Экологик аңлылык, фикерләү дәрәҗәсе, культуралылык – болар килеп туган хәлдән чыгуның бердәнбер юлы булып тора. Ә моның өчен балаларга кече яшьтән үк экологик тәрбия биреп кенә ирешергә мөмкин. Табигатьне күзәтү, аны өйрәнү, сакларга омтылу балаларның рухи дөньясын баета, уйларга өйрәтә.

Балаларга табигатьнең гүзәллеген, аның байлыгы белән таныштыру,файдалы үлән, чәчәк, җәнлек,бөҗәкләрне таный белергә өйрәтү, сакчыл караш тәрбияләү максатыннан, безнең балалар бакчасында да экологик тәрбия бирү эшенә нык игътибар ителде, үзләре алдында зур бурыч куеп, эшләрен планлы рәвештә алып бардылар. Белгәнебезчә балаларның сәламәтлеге, яшәеше турыдан-туры әйләнә-тирә мөхиткә бәйле. Шушыларны искә алып, тәрбияче балаларның яшь үзенчәлекләренә туры китереп, махсус экологик тәрбия бирү буенча еллык эш планнарын төзеде.

Бала иң беренче чиратта үзе яшәгән төбәкнең экологик хәлен белергә тиеш, шуның өчен дә зурлар төркемнәрендә җәй һәм көз фасылында чишмәләргә экскурсияләр оештырылды. Экскурсияләр, сәяхәтләр барышында күп кенә бурычлар үтәлә: күзәтүләр барышында һава үзгәрешләренә игътибар иттеләр. Үсемлек, бөҗәкләрне тышкы кыяфәтенә карап таныргa, исемен әйтергә өйрәнделәр. Шуннан чыгып:

- күңелгә ягымлы авазларны тыңлый белергә һәм аларны матур сүзләр белән әйтергә өйрәнделәр;
- табигать кочагында үзеңне дөрес тоту, җир-суны пычратмау, яшеллекне һәм җан ияләрен саклау кирәклегенә төшенделәр;
- табигатькә мәхәббәт, үсемлекләргә, төрле җан ияләренә сакчыл караш тәрбияләнде.

Ел саен зурлар төркемнәре белән һәр ел фасылын зур оешканлык белән каршы алдык. Мәсәлән, язны каршылаганда кошларга ата-аналар ярдәме белән оялар ясаттык. . Көзне каршы алганда чәчәк орлыклары җыйдык. Кышны каршы алганда исә, кошларга җимнәр салыр өчен җимлекләр ясаттык, агач төпләренә салкыннан сакланыр өчен кар өйдек.
Экологик тәрбия бирү эшендә быелгы уку елында бик күп күләмдә эш алып барылды.

Бүгенгесе көн кадагында «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законында һәм «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләр саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы»нда мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралганлыгын исәпкә алып, өченче бурычыбыз: **"Икетеллелеккә өйрәтүдә яңа УМК ын педагогик эшчәнлеккә кертү"**заман таләпләренә туры килгән УМК-материаллары кулланып, балаларга тәрбия-белем бирү эшен оештырдык. Бакчада балаларны рус теле һәм туган телдә өйрәтү, сөйләм телләрен ныгыту өчен шартлар булдырдык:

- Яшь үзенчәлекләренә туры килгән методик әсбаплар;
- Дидактик уеннар;
- Эшдәфтәре(балаларөчен);
- Аудиоматериал;
- Мультипликационсюжетлар;
- Күрсәтмә, таратмаматериаллар;
- Диагностикалар;
- Рус, татар телендә әкият персонажлары;

Бу уку елына әзерлекле керәбез.

| Төркемнәр | Югары дәрәҗә | Уртача дәрәҗә | Түбән дәрәҗә |
|---|---|---|---|
| Мәктәпкә әзерлек төркеме: | 100% | 0 | 0 |
| Зурлар төркеме | 75% | 25% | 0 |
| Уртанчылар төркеме | 50% | 50% | 0 |
| Балалар бакчасы буенча | 75% | 25% | 0 |

“Туган телдә сөйләшәбез” укыту методик комплекты буенча балаларның белем дәрәҗәләре түбәндәгечә:

| Төркемнәр | Югары дәрәҗә | Уртача дәрәҗә | Түбән дәрәҗә |
|---|---|---|---|
| Мәктәпкә әзерлек төркеме: | 73% | 27% | 0 |
| Зурлар төркеме | 80% | 20% | 0 |
| Уртанчылар төркеме | 75% | 25% | 0 |
| Балалар бакчасы буенча | 76% | 24% | 0 |

Балалар бакчасында сәламәтләндерү чаралары дәвамлы үткәрелә. Авырулар саны кимү тендециясендә:

Балаларның сәламәтлеген саклау күрсәткече

| еллар | Балалар бакчасы буенча |
|---|---|
| 2022 | 3,2 |
| 2023 | 4,2 |
| 2025 | 3,8 |

2025 елда мәктәпкә 5 бала китте. Балаларның мәктәпкә хәзерлек күрсәткечләре, белем дәрәҗәләре түбәндәгечә:
Югары: 83 %
Уртача:17 %
Түбән:0%
Бурычларыбызның берсе итеп, үстерешле тирәлек булдырып, балаларның иҗади сәләтләрен үстерүне куйдык. Балаларыбыз өчен бакчада барлык уңай шартлар тудырырга тырыштык. Иң югары таләпләргә китерелеп эшләнгән уен почмаклары, спорт белән шөгыльләнү почмагы, милли почмак бар. Бакчабызда балаларга әхлак тәрбиясе бирү эшен махсус программа буенча алып баруны дәвам итәбез.
Программа Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган “Гаиләдә, балалар бакчасында әдәплелек тәрбияләү” программасына, Р.Фәхреддиннең “Нәсыйхәт”, “Балаларга үгет һәм нәсыйхәт” китапларына нигезләнеп төзелде. Атнага бер мәртәбә әхлак дәресләре уздырылды.
Балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча тәрбиячеләр тарафыннан тематик-перспектив план төзелде. Шул план нигезендә тәрбиячеләр дәрес эшкәртмәләре төзеделәр.
Шулай ук балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча табышмаклар, тизәйткечләр, такмаклар тупланды.
Методик почмакта балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча шөгыльләр өчен кирәк булган күргәзмә материаллар, дидактик уеннар, юл макетлары, светофор, юл билгеләре, рульләр, милиция фуражкалары, юл күрсәтүче таяклар һ.б. тупланган. Тәрбиячеләргә, балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча ярдәмгә махсус әдәбият тупланган.
Мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасы структурасына карата Федераль Дәүләт Белем бирү Стандартлары нигезендә балалар бакчаларында балаларга туган телне өйрәтү, сөйләм үстерү, әдәби телдә сөйләшү күнекмәләре булдыру юнәлешен тормышка ашыруны максат итеп, ике дәүләт телендә дә иркен сөйләшергә, аралашырга өйрәтүдә, бәйләнешле сөйләм телен үстерү һәм сүз байлыгын арттыруда заманча технологияләр, мультимедиа чараларын, УМКны киң кулландык. Рус телен өйрәнүдә ирешелгән нәтиҗәләр:
Уртанчылар төркеме: югары – 50 %, уртача- 50 %.
Зурлар төркеме: югары – 100%, уртача- 0%.
Мәктәпкә әзерлек төркеме: югары – 86%, уртача – 14%

Ел дәвамында тәрбиячеләр җитәкчелегендә балалаларыбыз төрле конкурсларда катнаштылар.
«Символ года 2025»; “Муса Джалиль, жизнь как песня”- Төбәкара бәйгесендә 2 –дәрәҗә дипломы; Республикакүләм “Шәвәлидә кунакта” бәйгесе- Диплом;«Язык предков» - Төбәкара бәйгесендә 2 –дәрәҗә дипломы; Тәрбиячеләребез күрше район –күләм семинарларда катнаштылар. “ Татар малае, татар кызы 2025” район күләм бәйгедә катнашу. Онлайн олимпиада- 2 урын- Җәләлиев Раян; Район күләмендә уздырылган “ Воспитатель года – 2025”бәйгесендә 1нче урын
; Республика күләмендә дә уңышлы гына катнашу булды ; VII- Региональная научно-исследовательская конференция «Экология»-награждена дипломом 1 место. “ Самый лучшей Знайка по ПДД” II нче зона семинарында 3нче дәрәҗәдәге диплом;”Татарстан –фронту! Рисунок”-Шафиев Амир диплом; “Сәйяр” балалар һәм яшүсмерләр театрларының республика фестивалендә һәр ел саен актив катнашып призлы урыннар яулыйбыз.”

“Тиенкәй” балалар бакчасында укыту – тәрбия процессының, рухи-әхлакый тәрбиянең югары дәрәҗәдә куелуы һәм системалы алып барылуы балаларда әдәплелек, мәрхәмәтлелек, инсафлылык тәрбияли, аларны үз –үзләрен тота белергә, тирә яктагы матурлыкны күрергә, өлкәннәргә, иптәшләренә ярдәмчел, игътибарлы булырга өйрәтә.

Коллективның тырышлыгы белән бакча территориясендә җәй көне матур чәчәклекләр үстерелде, кыш көне кардан сыннар ясап куелды һәм район балалар бакчасы арасында 1 нче урынга лаек булдык.

Ел әйләнәсенә салынган бюджет мөмкинлекләреннән чыгып, балаларның туклану рационы ел дәвамында төрле ризыкларга бай булды. Балалар ел дәвамында яшелчә, җиләк-җимешләр белән тәэмин ителеп тордылар.

Балалар бакчасының материаль – техник базасын ныгытуда шактый эшләр эшләнде.

Балалар бакчасында әти-әниләр белән эш төрле формаларда алып барылды: анкеталар үткәрелде, актуаль темаларга консультацияләр бирелде, стендлардагы мәгълүматлар тулыландырылды, ачык ишекләр көне, бердәм бәйрәмнәр күңел ачулар үткәрелде. Әти-әниләр белән бергә 2 гомуми җыелыш үткәрелде. 2025 нче ел Россиядә Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы тынычлык һәм бердәмлек елы дип игълан ителде.Шул уңайдан Әти-әниләр арасында “Үз кулларың белән хәрби темага эшләнмәләр” ” дип исемләнгән бәйге уздырдык.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә, балалар бакчасында тәрбия-өйрәтү эше җитәрлек дәрәҗәдә куелган, балаларны өйрәтү, төрле яклап үстерү һәм тәрбияләү эшенә зур игьтибар бирелә, уңай шартлар тудырылган.

## Балалар бакчасының методик темасы:

«Социаль мөхиткә яраклашкан,сәламәт, культуралы,яшь үзенчәлекләренә туры килгән белем күнекмәләр үзләштергән, белем алганда УМК нигезләнеп ФДББС ,ФББП таләпләрен кабул итә алырлык шәхес тәрбияләү”

**Максат:** “Мәктәпкәчә яшьтәге балалар яшәеше өчен ФДББС ФББП

таләпләренә туры китереп уңайлы шартлар тудыру ;

ТР ның ике телен дә өйрәнү;

шәхес культурасы нигезләре өчен җирлек тудыру,

яше һәм шәхси үзенчәлекләре нигезендә баланың төрле яклап үсешенә ярдәм итү,

заманча җәмгыятькә яшәүгә һәм мәктәптә укуга әзерләү;

баланың тормыш иминлеген тәэмин итү;

Яшь буынга патриотик тәрбия бирү ;

## Коллектив алдында торган бурычлар:

1. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү процессын планлаштыруның мәктәпкәчә белем бирү оешмасында белем бирү программасына федераль дәүләт белем бирү стандартларына җавап бирерлек яңа формаларын эшебездә кулланып федераль белем бирү программасын гамәлгә ашыру.

2. Балаларны ике дәүләт телендә дә иркен сөйләшергә, аралашырга өйрәтүдә, бәйләнешле сөйләм телен үстерү һәм сүз байлыгын арттыруда заманча технологияләр, мультимедиа чараларын, УМК куллану.

3.Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга гаиләгә, туган якка, кечкенә ватанына мәхәббәт булдыру;
Яшь буынга патриотик тәрбия бирү.
Балаларга туган илгә һәм туган җиргә карата мәхәббәт тәрбияләү

4.Авыл җирлегенә хас һөнәр ияләрен өйрәтү аша балаланың танып-белү активлыкларын, кызыксынуларын, интеллектуаль үсешләрен тәэмин итүне дәвам итү.

## Педагогик кадрлар

| № п/п | Тәрбияченең исем, фамилиясе, отчествосы | Вазыйфасы | Туган елы | Белеме | Педагогик эш стажы | Квалификаци он категориясе |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Кадырова А.С. | Бакча мөдире музыкаль җит. | 07.06.1976 | Югары | 28/5 | 1-категорияле |
| **2.** | Халикова С.Г. | Тәрбияче<br>Рус теле Тәрбиячесе<br>Физ.ра инспекторы | 12.05.1966 | Махсус урта | 40\25 | Югары категорияле |
| **3.** | Салахова И.Г. | Тәрбияче | 29.09.1966 | Югары | 42\17 | 1-категорияле |
| **4.** | Насрутдинова Д.М. | Тәрбияче<br>Педагог психолог | 23.06.1983 | Югары | 23\6 | Югары категорияле |

## Педагогларның квалификация дәрәҗәсен күтәрү турында мәгълүмат

| № п/п | Ф.И.О. | Вазифасы | Белем күтәрү курслары<br>Үткән/үтәсе | Укыту оешмасы | Аттестация узган һәм узаргатиеш вакыты | Категориясе |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Кадырова А.С. | Музыка тәрбиячесе | 18.01.2024 | ТР мәгарифне үстерү институты | 2022/2027 | 1 |
| 2. | Халикова С.Г.. | Тәрбияче | 15.11.2019 | ТР мәгарифне үстерү институты | 2025\2030 | югары |
| 3. | Салахова И.Г. | Тәрбияче | 06.11.2022 | ТР мәгарифне үстерү институты | 2022/2027 | 1 |
| 4. | Насрутдинова Д.М. | Тәрбияче | 20.12.2023 | ТР мәгарифне үстерү институты | 2021/2026 | Югары |

## Тәрбиячеләрнең үзбелемен күтәрү буенча иҗади эш темалары

| № | Ф.И.О. | Темалары. |
|---|---|---|
| 1 | Салахова Ильхамия Галимовна | Балаларның сөйләм телен һәм уй-фикерләү сәләтләрен үстерү |
| 2 | Халикова Светлана Гариковна | Балаларның танып белү сәләтләрен үстерү |
| 3 | Насрутдинова Диляра Маратовна | Балаларда әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү |
| 4 | Кадырова Айгуль Салимулловна | Балаларның иҗади сәләтләрен үстерү |

## Экологик тәрбия

| айлар | Тәрбия чаралары | Күргәзмәләр |
|---|---|---|
| Август | Табигатьтәге үзгәрешләрне күзәтү; төрле табигый материаллар җыю | |
| Сентябрь | “Көзге урманга экскурсия” | “Яфраклар” |
| Октябрь | “Бакчабызга көз килде” (“Уңыш” бәйрәме) | “Бу нинди могҗиза?!” (Төрле яшелчәләрдән күргәзмә) |
| Ноябрь | “Канатлы дусларга ярдәм итик?!”(Бездә кышлаучы кошлар) | “Минем кунакларым” (Җимлектәге кошларны рәсемгә төшерү) |
| Декабрь | Кышкы авыл буенча экскурсия | “Авылда кыш” (рәсем конкурсы) |
| Январь | “Җәнлекләр кышны ничек уздыра?” | Табигый материалдан ясалган әйберләрдән күргәзмә |
| Февраль | “Урманны саклыйк!” | Макулатура тапшыру |
| Март | “Кайтыгыз,кошкайлыр” | “Яз килә”(рәсем конкурсы) |
| Апрель | Елгада боз китүен күзәтү. | |
| Май | Язгы урманга экскурсия. “Алдынгылар хәрәкәте эшчәнлегенә йомгак. | |

## Физик тәрбия
## Сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү

| Айлар | Эш төрләре |
|---|---|
| Август | Участокта физкультура мәйданчыгын , спорт инвентарьларын яңарту |
| Сентябрь | Балаларның физик эшчәнлеген бәяләү; ”Көзге корсс” |
| Октябрь | Эстафета ярышлары “Уңышны җыеп ал” |
| Ноябрь | Хәрәкәтле уеннар көне ”Спорт бәйрәме” |
| Декабрь | Кышкы уеннар өчен төрле корылмалар төзү. |
| Январь | Һавада спорт бәйрәме. |
| Февраль | “Саф һавада йөрибез” Бакча тирәсендә чаңгыда прогулка. |
| Март | “Уңган кызлар,җитез егетләр”. Эстафета ярышлары. |
| Апрель | Чишмәләр буена поход. Уен мәйданчыкларын җиһазлау. |
| Май | Балаларның физик эшчәнлеген билгеләү: “Язгы кросс” Урманга поход.”Мин хәрәкәткә-без хәрәкәттә” |

## Балаларга өстәмә белем белем бирү .

"Тиенкәй" балалар бакчасында шахмат түгәрәге оештырылды. Аны Салахова Ильхамия Галим кызы алып бара." Шахмат дөньясында"-дигән программасы төзелде. Балалар монда бик теләп катнашалар. Балалар түгәрәктә шахмат тактасы, фигуралар, әлеге уенның барлыкка килү тарихы һәм аны уйнау үзенчәлекләре белән танышалар. Мондый шөгылләр логик фикерләүне камилләштерергә ярдәм итә, хәтерне яхшырта, анализларга һәм фаразларга, игътибарлы булырга һәм максатчанлыкны үстерергә өйрәтә. Шахмат уйнау шулай ук балаларның уртак эшчәнлеген дә күз алдында тота: аларга аралашу күнекмәләрен үстерүгә ярдәм итә, бер-берсенә сакчыл карарга өйрәтә. Әлеге түгәрәккә йөрүче балалар инде төп терминнарны үзләштерделәр, барлык фигураларны да өйрәнделәр һәм бу уенны иркен, зур теләк белән уйныйлар.

## Әхлак тәрбиясе

## Патриотизм, гуманлылык, туган телгә мәхәббәт тәрбияләү

| айлар | бәйрәмнәр | Әдәплелек дәресләре |
|---|---|---|
| Сентябрь | "Белем бәйрәме" | Табигатькә көз килде<br>(Туган җиргә,<br>табигатькә мәхәббәт тәрбияләү) |
| Октябрь | "Бакчабызга көз килде" | Өлкәннәргә хөрмәт күрсәтик. Һөнәрләр. |
| Ноябрь | "Дуслык белән көчле без"<br>"Алдынгылар хәрәкәте" | 4 ноябрь- халыклар бердәмлеге көне<br>6 ноябрь- ТР<br>Конституциясе көне |
| Декабрь | "Яңа ел белән!"<br>( Әкияттә кунакта) | Халкыбыз йолалары,<br>милли бәйрәмнәре |
| Январь | "Юлда да акыл кирәк!" | Хезмәт төбе хәзинә |
| Февраль | "Батырлыкта матурлык"<br>"Алдынгылар хәрәкәте" | Туган өем- туган җирем- туган илем<br>Ватанны саклаучылар көне |
| Март | "Кайтыгыз, кошкайлар!" | Кече туганнарыбыз.<br>Нәүрүз килә! |
| Апрель | "Космонавтика көне"<br>"Алдынгылар<br>хәрәкәте"<br>"Без Тукай оныклары" | 2 апрель- балалар<br>китабы көне<br>Сөекле туган телем |
| Май | " Бөек Җиңү көне"<br>"Алдынгылар хәрәкәте" | Табигатьтә үзеңне<br>тоту кагыйдәләре.<br>Матур җәй, кил безгә! |

## Ата- аналар белән эш

| № | Чаралар | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | “Белем бәйрәме”ндә катнашу | 1 сентябрь | Тәрбиячеләр, Муз. Җитәкчесе |
| 2. | Әти-әниләрнең һөнәрләре. | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр |
| 3. | Әти-әниләр катнашында календарь бәйрәмнәр уздыру | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр Муз.җитәкчесе |
| 4 | Әти-әниләр катнашында төрле күргәзмәләр оештыру | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр |
| 5. | Авылда булган оешмаларда экскурсияләр | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр |

## Педагогик киңәшмә

| Эш төре | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|
| 1. Яңа уку елына киңәшмә рәисе һәм сәркатиб сайлау.<br>2. 2025-2026 уку елына еллык эш план.<br>3. Бакчаның үсеш программасы<br>4. Бакчаның белем бирү програмасы.<br>5. Балаларны төркемнәргә күчерү. | август | Мөдир-Кадырова А.С. |
| 1. Алдагы педагогик киңәшмә нәтиҗәләре.<br>2. Балалар бакчасында максатчан экскурсияләр<br>3. Туган телне үстерү, милли үзаң һәм патриотизм тәрбияләү<br>4. Диагностика нәтиҗәләре | сентябрь | мөдир- Кадырова А.С.<br>тәрбияче Насрутдинова Д.М.<br>тәрбияче Салахова И.Г.<br>тәрбияче Халикова С.Г. |
| 1. Алдагы педагогик киңәшмә нәтиҗәләре.<br>2. Яңа елга зерлек<br>3. Шөгыльләр үткәрүдә уен эшчәнлегенең роле | декабрь | мөдир- Кадырова А.С.<br>Насрутдинова Д.М. |
| 1. Алдагы педагогик киңәшмә нәтиҗәләре.<br>2. Баланы мәктәпкә әзерләүдә тәрбиячене роле”<br>( үзенең эш тәҗрибәсеннән) чыгыш<br>3. "Балаларны ана телендә сөйләшергә өйрәтү" | февраль | мөдир- Кадырова А.С<br>Халикова С.Г.<br>Салахова И.Г. |
| 1. Үсеш программасына һәм еллык планга нәтиҗә<br>2. Балаларның диагностик нәтиҗәләре.<br>3. җәйге чорга эш планын булдыру | май | мөдир- Кадырова А.С.<br>Тәрбияче Насрутдинова Д.М.<br>Тәрбияче-Салахова И.Г. |

## Педагогик кадрлар белән эш

| Эш төре | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|
| УМК буенча стендларны яңарту | Ел дэвамында | Мөдир Кадырова А.С. |
| Уен почмакларын төрле атрибутлар белән тулыландыру | Ел дэвамында | |
| Юл йөрү кагыйдәләре почмагын тулыландыру | Ел дэвамында | |
| Бэйрәмнәргә әзерлек | Ел дэвамында | |
| Тәрбиячеләрнең төрле район, республика конкурсларында, семинарларда катнашуы | Ел дэвамында | |
| Дидактик уеннар, лэпбуклар булдыру | Ел дэвамында | |
| Һөнәр ияләре почмагын булдырып төрле дидактик уеннар ясау. | Ел дэвамында | |
| Тематик тикшерү (мәктәпкә хәзерлек төркеме)<br>“ УМК куллану” | декабрь | |
| | | |

## Производство киңәшмәләре

| Эш төре | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|
| 1. Киңәшмә рәисе һәм сәркатибы сайлау<br>2. Хезмәтне саклау<br>3. Антикоррупция эшчәнлеге<br>4. Янгын куркынычсызлыгы, эвакуация планын булдыру<br>5. Белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасында килеп чыккан бәхәсләрне җайга салу буенча комиссия әгъзаларын сайлау<br>6. Антитеррор эшчэнлеге буенча план | сентябрь | Мөдир- Кадырова А.С. |
| 1. Алдагы җыелыш карары үтәлеше<br>2. 2025-2026 нчы уку елы өчен чираттагы ялграфигын төзү.<br>3. Куркынычсызлык кагыйдәләре<br>4. “Алдынгылар “хәрәкәте эшчәнлеге турында | декабрь | Мөдир- Кадырова А.С. |
| 1. Алдагы җыелыш карары үтәлеше<br>2. Чираттагы яллар графигын карау<br>3. Җәйге чорда хезмәткәрләрнең эш бүленеше<br>4. Җәйге сәламәтләндерү чорында куркынычсызлык кагыйдәләре | май | Мөдир-Кадырова А.С. |

## Әти-әниләр җыелышы

| Темасы | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|
| Катнаш төркем 1-3 яшь | | |
| 1. Әти-әниләр комитеты председателе һәм әгъзаләрен сайлау.<br>2. 2025-2026 нчы уку елына бурычлар<br>3. Балалар бакчасында дидактик уеннар.<br>4. Балалар бакчасында адаптация чоры | октябрь | Тәрбияче Салахова И.Г.<br>Тәрбияче Насрутдинова Д.М. |
| 1. Сүзле уеннар кулланып балаларның бәйләнешле сөйләм телен устерү<br>2. Сәхнәләштерү эшчәнлеге аша балаларның сөйләм телен үстерү | апрель | Тәрбияче Насрутдинова Д.М.<br>Тәрбияче Салахова И.Г. |
| Катнаш төркем 3-7 яшь | | |
| 1. Әти-әниләр комитеты председателе һәм әгъзаләрен сайлау.<br>2. Әти-әниләр белән УМК буенча еллык эш планы<br>3. Халык аваз иҗаты әсәрләренең сөйләм теле үстерүдә булган әһәмияте | октябрь | Тәрбияче Салахова И.Г.<br>Тәрбияче<br>Халикова С.Г. |
| 1. Балаларга хезмәт тәрбиясе бирү<br>2. Туган телне һәм гореф-гадәтләрне саклауда гаиләнең роле<br>3. Сөйләм үстерүдә бармак уеннарының әһәмияте | декабрь | Тәрбияче Салахова И.Г.<br>Тәрбияче<br>Халикова С.Г. |
| 1. Баланы ике телгә ничек өйрәтергә<br>2. Түгәрәк өстәл "Туган телне саклыйк"<br>3. Баланы мәктәпкә әзерләү | апрель | Тәрбияче Салахова И.Г.<br>Тәрбияче Халикова С.Г. |
| 1. "Алдынгылар" хәрәкәте эшчәнлегенә йомгак | Май | Тәрбияче Халикова С.Г. |
| Гомуми әти-әниләр җыелышы | | |
| 1. Гомуми ата-аналар җыелышы рәисен һәм Сәркатибен сайлау<br>2. Үткән уку елына анализ һәм яңа уку елына бурычлар<br>3. ОРВИ, грипкка каршы прививкалар<br>4. Белем бирү мөнәсәбәтләре катнашучылары арасындагы низагны җайга салу буенча комиссия<br>5. Тәрбияләнүчеләрнең тукклануын контрольдә тоту<br>6. Федераль белем бирү программасы мәсьәләсе буенча анкеталау | сентябрь | Мөдир Кадырова А.С.<br>Мөдир Кадырова А.С.<br>Мед.сестра<br>Мөдир Кадырова А.С. |

| | | |
|---|---|---|
| 1. Җәйге чорга эш планы.<br>2. "Телне саклап калу - халыкны саклау"<br>3. Хезмәт тәрбиясе<br>4. Баланы мәктәпкә әзерләү.<br>5. Юл-транспорт җәрәхәтләрен булдырмау | май | Салахова И.Г.<br>Халикова С.Г.<br>Насрутдинова Д.М.<br>Кадырова А.С.<br>Полиция хезмәткәре |

**Ата-аналар белән УМК буенча эш төрләре**
**(Работа с родителями по УМК)**

| № п/п | Содержание | Үтәү вакыты |
|---|---|---|
| 1 | Әти-әниләрне анкеталаштыру. Тема: Федераль белем бирү программасы | сентябрь |
| 2 | Күчмә папканы тулыландыру: “Рус телен өйрәнгәндә карау өчен киңәш ителә торган мультфильмнар исемлеге” («Перечень мультфильмов, рекомендуемых детям для просмотра, при обучении русскому языку») | октябрь |
| 3 | Җыр сүзләрен өйрәнү, көз һәм яңа ел бәйрәменә персонаж костюмнары әзерләү. (Разучивание слов, песен, приготовление костюмов персонажей к празднику осени, к Новому году) | октябрь, декабрь |
| 4 | Рәсем күргәзмәсе оештыру: “Рус телен өйрәнүдә гаилә ничек үз баласына ярдәм итә” (Выставка семейных рисунков «Как я помогаю своему ребенку в изучении русского языка») | январь |
| 5 | «Папы всякие важны»: рус телендә шигырьләр, җырлар өйрәнү | февраль |
| 6 | “Гаилә бәйрәме” Бәйрәмгә хәзерлектә катнашу. Рус телендә шигырьләр, җырлар өйрәнү. ( Участие в подготовке праздника: Разучивание стихотворений, песен на русском языке приготовление костюмов для праздника.) | март |
| 7 | Сөйләм телен үстерүдә “Бакчам календарен куллану” | Ел дәвамында |
| 8 | Ата-аналар соравы буенча консультацияләр оештыру. (Проводить индивидуальные консультации по вопросам родителей) | Ел дәвамында |
| 9 | Ата-аналар өчен мәгълумат стендын яңарту: «Изучаем русский язык», “Туган телдә сөйләшәбез”, “Авазларны уйнатып”, “ФДББС”, ФББП | Ел дәвамында |
| 10 | Күчмә папканы тулыландыру: «Бармак уеннары” зурлар төркемдә (“Пальчиковые игры» в старшей группе.) | Ел дәвамында |
| 11 | Күчмә папка ясау: “Гаиләдәге һөнәр ияләре” | Ел дәвамында |
| 12 | Күчмә папкасын тулыландыру: “Безнең яраткан шигырьләребез” зурлар-мәктәпкә хәзерлек төремендә. ( «Наши любимые стихотворения» в старшей- подготовительной группе.) | Ел дәвамында |
| 13 | Күчмә папкасын яңарту: “Сөйләм теле өчен уеннар һәм уен күнегүләре” мәктәпкә хәзерлек төркемендә ( «Игры и игровые упражнения для развития речи» в подготовительной группе.) | Ел дәвамында |
| 14 | “Әти-әниемнең һөнәре” кул эшләреннән күргәзмү | гыйнвар |
| 16 | “Авыл хуҗалыгы транспортлары” кул эшләре күргәзмәсе | февраль |

**Кошман төп белем бирү мәктәбе**
**белән хезмәттәшлек итү**
**2025-2026 нчы уку елы.**

| **№** | **Эш төре** | **Вакыты** | **Жаваплы** |
|---|---|---|---|
| 1 | Мәктәпкә экскурсияләр һәм максатчан прогулкалар: | Сентябрь | Тәрбиячеләр |
| 2 | Яңа уку елы башланганда «Белем» бәйрәмендә катнашу. | Сентябрь | Тәрбиячеләр |
| 3. | Укытучылар коллективын һөнәри бәйрәмнәре белән котлау. | Октябрь | Тәрбиячеләр |
| 4. | Мәктәп алдынгылар хәрәкәте белән тыгыз элемтәдә тору | Даими | Тәрбиячеләр”Алдынгылар” җитәкчес |
| 5. | Мәктәп белән таныштыру; класс, китапханә, спортзал,компьютер бүлмәсе. | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр |
| 6. | I сыйныф укучыларының укулары белән кызыксынып тору, дәресләрендә булу. | Ел дәвамында | Педагогик коллектив |
| 7. | 1 нче сыйныф укучыларының «Әлифба» бәйрәмендә катнашып, котлау | Февраль | Тәрбиячеләр |
| 8. | Башлангыч сыйныф укытучыларын ата-аналаржыелышына, белем бирү эшчәнлекләренә чакыру, рәсемнәр күргәзмәсе. | Даими | Мөдир, тәрбиячеләр |
| 9. | Мәктәпнең спорт мәйданчыгы белән таныштыру, спорт ярышларын карарга алыпчыгу. | Кыш айларында | Тәрбиячеләр |
| 10. | Балаларны мәктәпкә әзерләү һәм озату кичәсеуздыру « Сау бул бакча.» | Май | Тәрбиячеләр |

# “Ачык ишекләр” көне.

| № | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | “Ачык ишекләр көне”. Рәсем ,кул эшләре күргәзмәләре. “Алдынгылар” хәрәкәте буенча чара. | Январь - февраль | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 2 | Рус теле буенча “Ачык ишекләр” көне, көн дәвамында балалар белән рус телендә аралашу | | тәрбияче |
| 3 | «Сәламәт булып үсәбез»Физкультура, музыка шөгылләрен карау, режим моментын: чыныктыру, саф һавада булу, иртәнге гимнастика. | | бакча мөдире, тәрбияче |
| 4 | Математика иленә сәяхәт. (шөгыль) ачык чара | | Бакчамөдире, тәрбияче |
| 6 | Иҗади отчет атналыклары | | Бакчамөдире, тәрбияче |

# Күргәзмәләр

| № | Үткәреләчәкчаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Җәйге чәчәклләрдән, уңышлардан композицияләр күргәзмәсе | сентябрь | Тәрбияче |
| 2 | «Алтын көз»- балаларның тематик рәсем күргәзмәсе | октябрь | Тәрбияче |
| 3 | Әниләр көненә багышланган «Минем яраткан әнием» дигән рәсем күргәзмәсе | ноябрь | Тәрбияче |
| 4 | Рус халык әкиятләре буенча ясалган рәсем һәм кул эшләре күргәзмәсе | март | Тәрбияче |
| 5 | Җиңүнең 81 еллыгына багышланган рәсем күргәзмәсе | май | Тәрбияче |
| 6 | « Матур Җәй, кил безгә!”» - балалар рәсем күргәзмәсе | май | Тәрбияче |

# Укыту-тәрбия процессында педагогик контроль

| № | Чаралар | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| **1.** | | | |
| а | Барлык төркемнәрнең яңа уку елына әзерлекләрен тикшерү | уку елы башында | мөдир |
| б | Тәрбиячеләрнең тематик, календар планнарын тикшерү. Иртәнге гимнастика, эшчәнлекләрне, режим моментларын карау. | ел дәвамында | мөдир |
| в | Төркемнәрдә чыныктыру чараларын үткәрүне контрольда тоту. | ел дәвамында | мөдир, |
| г | Барлык төркемнәрдә дә тәрбия һәм белем бирү эшенә контрольлек итү. | ел дәвамында | мөдир |
| | <u>**Тематик тикшерүләр**</u> | | |
| **2.** | **Тема:“Рппс төркемнәренең мкдо сыйфаты күрсәткечләренә туры килүен тәэмин итү "** | ноябрь | мөдир |
| | **Тема:“Төркемдә сәнгать эшчәнлеген формалаштыру буенча шартларны анализлау”** | февраль | мөдир |

Лист согласования к документу № 15 от 28.10.2025
Инициатор согласования: Кадырова А.С. Заведующая
Согласование инициировано: 28.10.2025 14:56

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кадырова А.С. | | Подписано<br>28.10.2025 - 14:56 | - |